## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

### КАРАР

08.07.2025 ел №69

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 24 февралендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында аңлатмаларга үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2019 елның 23 декабрендәге 169од номерлы боерыгы нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

### КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 24 февралендәге 20 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2.2 пункты. Регистрга кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү өчен җаваплы зат итеп район Советы аппаратының юридик бүлеге баш белгече Мингазова Гүзәл Нияз кызын билгеләргә.»;

1.2. «2.3 пункты. Район Советы аппаратының юридик бүлеге белгече вакытлыча булмаган очракта, әлеге карарның 2.2 пунктында каралган вәкаләтләр район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы Бузина Нәзирә Камил кызы тарафыннан тәмамлана, дип билгеләргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлеше контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы вазифаларын башкаручы Р.И. Закиров